**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Үчәлле авылы № 101 « 27 » ноябрь, 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2014 елның 24 ноябрендәге 121 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында (18.08.2015 №145, 02.08.2017 №61, 10.11.2018 №117, 25.06.2019 №147, 05.11.2019 №158, 02.10.2020 №10, 05.08.2021 №34 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Үчәлле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2014 елның 24 ноябрендәге 121 номерлы карарына (18.08.2015 №145, 02.08.2017 №61, 10.11.2018 №117, 25.06.2019 №147, 05.11.2019 №158, 02.10.2020 №10, 05.08.2021 №34 карарлар редакциясендә) түбәндәге редакциядә 2 пунктның 2 пунктчасын бәян итеп, үзгәрешне кертергә:

«2) торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган, торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган җир кишәрлекләреннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) кадастр бәясенең 0,3 проценты;».

2. Әлеге карар “Маяк” район газетасында басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә 2024 елның 1 гыйнварыннан кагыла.

3. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Г.М.Төхвәтуллина